Февраль 2011, 3 выпуск
*МАОУ ГИМНАЗИЯ-ИНТЕРНАТ №4'КИРОВСКОГО РАЙОНА Г.*

# Диалог

***Книги - окна, сквозь которые выглядывает душа.***
***Бичер Генри Уорд***



**Здравствуйте! В очередной раз я приветствую вас на страницах нашей ежемесячной школьной газеты. Я очень рада, что Вы, уважаемый читатель, вновь взяли её в руки. В этот раз мы хотим поговорить на очень важную и серьёзную тему—книга. На страницах этой газеты вы найдёте много новой и полезной информации. Обещаю: будет интересно.**
**Настя Ахтямова.**

**Отраженье исчезнувших лет,**
**Облегченье житейского ига.**
**Вечных истин немеркнущий свет —**
**Это книга. Да здравствует книга!**
**Неустанных исканий залог.**
**Радость каждого нового сдвига,**
**Указанье грядущих дорог—**
**Это — книга. Да здравствует— книга!**
**Чистых радостей светлый исток,**
**Закрепленье счастливого мига.**
**Лучший друг, если ты одинок, —**
**Это книга. Да здравствует книга!**

# Китап -безнең дустыбыз-

Гимназия укучыларыбыз язган «Минем тормышымда китап» исемле иншалардан өзекләр тәкдим итәбез.

«Дөнядa китаптан башка яшәү мөмкин түгелдер, минемчә. Китап ул-укытучы, ул бик күп акыл хәзинәсе белән тупланган. Ул хәзинәне бернинди компьютер да, телевизор да алмаштыра алмый. Мингалимова Айгел

«Китап ярдәмендә без белем дөньясын гизәбез. Әдәби китаплар укып, гүзәллекне күрергә, яхшылыкны яманлыктан аерырга өйрәнәбез. Матур әдәбият безгә фикеребезне тупларга, тел байлыгыбызны арттырырга ярдәм итә».– Нургалеева Г



«Минем уйлавымча, балада кечкенәдән үк китапка карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләргә кирәк. Укыганда баланың фантазиясе үсә, ул матуррак сөйләшә, уйлый, фикер йөртә башлый, үзенә ниндидер яңалыклар ача»- Гайнуллина Л

«Хәзерге заманда электрон китаплар модага керде, Әйе, алар уңайлы, дүрт томлы китапны үзең белән йөртә алмыйсың, ә электрон китап авыр түгел. Тик мин аларны укый алмыйм. Минем өчен иң мөһиме—китап битләрен сизеп, автор белән әңгәмә кору»- Аглиуллина А.

# 10 интересных фактов о книге...



1. Учёные подсчитали количество всех художественных, публицистических и научных трудов в мире. Оказалось, что общее количество книг на Земле составляет 129 864 880.

2. Самой древней книгой на Земле считается так называемый папирус Присса. Он был создан в 3350 году до нашей эры. Эта книга была найдена в одной из пирамид города Фивы. Интересно, что тема папируса Присса весьма актуальна и сегодня. Это так называемый конфликт поколений. Автор самой древней книги жалуется на то, что молодежь невоспитанна, ленива и порочна. Как видим, за пять с лишним тысячелетий ничего не изменилось.

3. Опечатки - один из самых главных врагов книгоиздателя. Разумеется, большого принципиального вреда они не приносят, зато как досадны! В шестнадцатом веке появилось даже выражение «дьявол опечатки». Связано оно было с тем, что в одном из церковных трактатов оказалось невероятное количество опечаток. Издателям ничего не оставалось, как объяснить этот прискорбный факт тем, что их сделал сам дьявол для того, чтобы читатели отказались читать бессмысленный текст.




4. Самая дорогая в мире книга - «Лестерский кодекс». Это научный трактат Леонардо да Винчи, посвященный «воде, земле и небесным телам». В настоящее время его владельцем является Билл Гейтс. Он приобрел эту книгу за двадцать четыре миллиона долларов. Чтобы прочесть «Лестерский кодекс», обязательно нужно вооружиться зеркалом: книга напечатана зеркальным шрифтом.

5.Литературоведы подсчитали, что в книгах Шекспира слово «любовь» упоминается 2259 раз, в то время как «ненависть» произносится всего 229 раз.

6.В список самых скучных книг, составленный британской компанией «Teletext» в 2007 году, вошли «Война и мир», «Преступление и наказание», «Улисс» Джеймса Джойса, «Облачный атлас» Дэвида Митчелла, «Сатанинские стихи» Салмана Рушди, а также «Алхимик» Пауло Коэльо и «Гарри Поттер и Кубок Огня».

7.Нынешний всплеск литературы о вампирах далеко не единичный. В 20-30-е годы восемнадцатого века книжные дома Европы наперебой печатали «вампирские» романы и даже научные трактаты о вампирах. Только за один год вышло более двадцати книг на эту животрепещущую тему.

8.Один из самых больших гонораров за книгу был выплачен римским императором Марком Аврелием. Поэт Оппиан за каждую строчку двух своих поэм о рыбной ловле и охоте получил по золотой монете. Общее количество строчек в двух поэмах составляло двадцать тысяч.

9.Самая большая книга в мире была представлена в этом году на Международной книжной выставке в Гаване. Сборник высказываний известных людей имеет 380 сантиметров в длину и 350 сантиметров в высоту.

10.Что касается самых читаемых книг в мире, то пальма первенства, бесспорно, принадлежит Библии. Ее общий тираж - шесть миллиардов экземпляров. На втором месте - цитатник Мао Цзэдуна, а третье место досталось «Властелину колец».

# Мәңгелек хәзинә

**Гыймадиева Гүзәл Илдусовна,**
4 нче гимназия-интернатның китапханә мөдире

Моннан ике мең ел өлек яшәгән патшалар, фараоннар китапханәләрне үзләренең сарайларына караганда да затлырак итеп төзегәннәр. Кеше гомеренең бик тә кыска икәнең, кеше акылын, кеше аңын, кешелек хәтерен бары тик Китап аша гына саклап калырга һәм киләчәк буыннарга тапшырырга мөмкин булуын бик яхшы аңлаган алар.

Гомер-гомергә безнең халык та китапка гаҗәеп зур хөрмәт белән караган. Һәрбер татар өендә китап иң кадерле урында ипи белән бер дәрәҗәдә хөрмәтләп сакланган. Бу турында без горурланып сөйлибез. Эмма еллар узган саен әлеге горурлык хисенә борчу хисләре дә өстәлә бара. Соңгы берничә дистә ел эчендә китапка булган карашның кискен үзгәрүен барыбыз да күреп торабыз. Минемчә, китапның киләчәге бөтенләй үк өметсез түгел. Сонгы елларда халкыбызның үз туган теленә, гореф-гадәтләренә, тарихына сусаганны күрү, милләттәшләребез күңелендә милли горурлык хисе уяна башлавын тою бик тә куанычлы хәл. Ә халык тарихын, аның рухи байлыгын өйрәнү өчен иң кулай урын – китапханә.

Китап язмышы да кеше язмышы кебек шул. Алар да дөньяга килә, аларны да кыерсыталар, зинданнарга ябып куялар, кайберләрен кирәксә-кирәкмәсә дә күккә чияләр, ә кайберләрен учакларга салалар. Китап киштәләре яныннан узган чакта тукталып, китапларны караганда, уйга чумып каласын. Берсенең битендәге мәкалә лезвия белән киселгән, икенчесен бите бөтенләй умырып алынган... Бу китаплар безгә гасырлар үтеп, Сугыш афәтләре аша исән-сау килеп җиткәннәр! Берничә юл сүзне күчереп язарга иренгән “акыл иясе” шулай итеп үткән буын белән киләчәк буын арасындагы чылбырны, бәйләнешне өзә. Мин ул кешене аңламыйм, аңлый да алмыйм.

Урамнарга чыккач, кешеләрнең йөзенә игътибар беләнрәк карагыз әле! Әгәр дә каршыгызга очраган кешенең йөзендә яктылык, күзләрендә нур күрсәгез, ялгышмассыз, бу акыллы китап битләреннән күчкән яктылык – иман нуры булыр. Ә инде кара коелган, явыз эшләр белән мавыгып йөргәннәр арасында, күпме эзләсәгез дә, китапханәгә йөрүчеләрне очрата алмассыз.

Бу дөнъяда китаптан да яхшырак юлдаш, китаптан да ышанычлырак иптәш юк. Дусларым хыянәт иткән чаклар булды, әмма китаплар миңа беркайчан начарлык кылмадылар, начарлыкка өндәмәделәр. Китаплар – безнең рухи байлыгыбыз. Фараон Рамзес II нең китапханәсе ишеге өстенә “Җан дәвасы”, дип язылган.

Дөнъяда югалып калмас өчен, дөрес карар кабул кабул итәр өчен әйләнә-тирәдә нинди үзгәрешләр булуын аңларга кирәк. Моны тирән белемле кеше генә эшли ала. Китапханәләрнең ишекләре һервакыт ачык булганда гына, алар заманча җихазландырылганда гына безнең укучыларыбыз олуг әдипләребезнең мәнге үлмәс иҗатлары белән танышып барганда гына, фән, мәдәният, үткән тарихыбызны өйрәнгәндә генә җәмгыятебез алга таба үсәр.

Гомүмән, киләчәккә кешелекне зыялылар да алып бармаса, ( ә хәзер бу бик сирәк күренеш) һичшиксез бу вазифа китапханәчеләргә, эрудицияле, киң карашлы, зур проблемалар чишүгә һәм заманның бөтен сорауларына җавап бирергә сәләтле кешеләргә йөкләнә.

***Кулларыма изге китап алып,***

***Тибрәткәндә бала бишеген,***

***Серле әкиятләрне укыганда,***

***Йоклап киткән минем нәнием.***

***Тәүге тапкыр мәктәп бусагасын***

***Атлап кергән чакны онытмыйм.***

***Укытучымның кулына китап тотып,***

***Белем биргән көнен хәтерлим.***

***Авыр чагым булса, китап алып,***

***Кайгыларны читкә куямын,***

***Китаплардан, бары китаплардан***

***Мин үземә ләззәт аламын.***


***Китапханәче һөнәрен данлар өчен***

***Олы йөрәкле буллу кирәктер.***

***Китаплардан җыйган җылы хисне***

***Түкми-чәчми генә***

***Өләшергә, бәлки кирәктер...***





РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН

# Балаларга үгет-нәсыйхәт

## Тәрбияле бала

«Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмать-ләреннән кадерлебулган нәрсә, тәрбияле баладыр. Тәрбияле бала, дөнъяда җанга шатлык вә ахирәттә йөзгә аклык китерер.

Тәрбияле бала булырга һәр баланың кулыннан килер һәм көче җитәр. Атам вә анам шатлансын, кешеләр дә миңа рәхмәт әйтеп, мине яратсыннар һәм мине күчергеч итеп сөйләсеннәр, дигән балаларның барчасы тәрбияле бала була белерләр».

## Гыйлем

Гыйлем–күңел күзен ачар, наданлык карангылыгын җибәрер, олы дәрәҗәләргә ирештерер, дошманнарга каршы корал булыр, дөньяда тору юлларын белдерер.

Гыйлемле кешеләргә карап, аз белемле булудан оялмагыз, әмма белергә кулыгыздан килә торган нәрсәләрне белми калудан оялыгыз.

Гыйлемне һәрвакыт сөегез, Өйрәтелгән нәрсәләрне ихлас белән тыңлагыз, кирәкләрен өйрәнегез.

## КИТАП УКУ

Гүзәл китаплар—гаҗәеп эшләрне күрсәтүче көзге, аулакта сердәш, ялгызлыкта иптәш, гаҗизлек вакытында ярдәмче, кыйгылы вакытта шатлык китерүче, үткән заман хәлләрен сөйләп торучы».

Фикерләрне нурландырырлык, холыкларны күркәмләүгә ярдәм итәрлек, акылларны арттырырлык китапларны сайлап укыгыз, башкаларыннан ерак булыгыз, Файдалы китапларны уку күңелгә шатлык китерер, фикергә азык булыр, зиһенгә куәт кертер.



«Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам
Матурлыкны күреп төзләнәм.
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм…
Разил Вәлиев

« Разил Вәлиев—танылган язучы, шагыйрь , Җәмагать эшлеклесе, халык аның җырларын бик яратып тыңлый, тыңлап кына калмый, отып алып, үзе дә җырлый, Татарстанның халык депутаты буларак Разилнең һәрвакыт төпле фикере, саллы сүзе бар. Бәлки, кайчакта Разил хискә бирелеп, шагыйрләрчә кайнарланып та киткәлидер, Әмма шунысы ачык: ул һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән халык язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, туган мәдәниятебез , телебез, гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырыша.»

Минтимер Шәймиев

Ике дистәдән артык китап, дүрт пьеса, йөзләгән җырлар авторы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган җәмәгать эшлеклесе Разил Велиевнең татар милләте, татар тарихы, татар мәдәнияте өчен янып йөрүенә, бу өлкәдә куйган хезмәтләренә дөнья җәмәгатьчелеге дә югары бәя бирде. Ул “Планетада цивилизацияне, яшәешне һәм мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә керткән хезмәтләре өчен “Халыкара көмеш медаль белән бүләкләнде. АКШның һәм Англиянең биографик үзәкләре Разил Вәлиевне үзләренең идарә әгъзалары итеп сайладылар, дөньякүләм танылган “Кем ул кем” дигән энциклопедиядә аның биографиясен бастырып чыгардылар. Ә 1993 елда АКШның Төньяк Каролина шәһәрендәге биографик институт Разил Вәлиевкә «XX гасыр кешесе» дигән мактаулы исем бирде.

# ЯЗ .

***Утызы да тулмый февраль***
***китkән…***
***Урамнарга шыплап март тулган.***
***Агачларның саллы җәясенә***
***Ук түгел лә...яфрак тартылган.***

***Карлагар да безгә каркылдамый…***
***Без мәңгелек инде бу җирдә.***
***Бер туйганчы күккә карыйк әле***
***Ике кулны куеп бөергә***


***Кайгыларны салыйк гөрләвеккә,***
***Тургай итеп чөйик шатлыкны!***
***Яз хәбәрен ишетеп барча кошлар***
***Безнең якка таба ашыкты.***

***Такса таксын дошман төрле ис-***
***ем…***
***Бар табигать безне үз итә…***
***Безне сагынып кошлар килә бүген,***
***Күңелләрдә бүген боз китә.***

***Рәзил Вәлиев***







**Руководитель проекта:** Гимадиева Г.И
**Редакторы:** Ахтямова Анастасия, Иванова Татьяна, Нигматзянова Регина , Альбина Шакирова